**СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

# КАРАР

«24» июль 2026 ел №38

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге Советы нигезендә **карар кылды**:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә чокырларны ремонтлау.
- «Октябрьский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Октябрьский бистәсендәге («Форест»торак комплексы) балалар бакчасына машина кую һәм керү юлларын төзү.

2. Октябрь авыл җирлеге башкарма комитетына җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Октябрьский бистәсе, Беренче Май урамы, 5 йорт, Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Октябрьский бистәсе, Беренче Май урамы, 2 нче йорт (Октябрь авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).

**Октябрьский авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.В. Евдокимова**

ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ